**ГЛАВА**
**Алешкин-Саплыкского**
**сельского поселения**
**Дрожжановского муниципального**
**района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Чүпрәле муниципаль районы**
**Алешкин-Саплык**
**авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**422478, Россия, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с. Алешкин-Саплык, ул. Школьная, д.3а**
**тел. (84375) 37-5-35, 37-5-49, факс. 37-5-36**
**E-Mail: AlSap.Drz@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 июнь 2020 ел №13

Йорт хайваннарын урамда йөртү өчен урыннар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль Закон, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 ел, № 489-ФЗ Федераль закон, авыл җирлеге Уставы нигезендә, Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын урамда йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

-хуҗасы милкендә яки кулланышта булган җир кишәрлекләре;

- бордникларда һәм аларның хуҗалары күзәтүе астында кешеләр күпләп җыелмаган авыл җирлеге территориясендәге буш урыннар, торак сектор артында урнашкан урыннар.

2. Балалар һәм спорт мәйданчыкларында, парклар, скверлар, массакүләм ял итү урыннарында, балаларга белем бирү һәм дәвалау учреждениеләрендә, мәдәният объектларына якын территорияләрдә, кибетләрдә, хайваннар белән бергә бару өчен махсус объектлардан тыш, йорт хайваннарын ирекле йөртүне тыярга.

Әлеге пунктның гамәлдә булуы поводырь этләренә кагылмый.

3. Җирле үзидарә органы карары белән хайваннарны урамда йөртү өчен рөхсәт ителгән урыннардан читтә йөртүгә, юл куймаска.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Алешкин-Саплык авыл җирлеге башлыгы: П.Н.Артемьев